## *Мәхәббәт маҗарасы*

Пар табуның, яр табуның
Күп бит аның төрләре:
Һәр былбыл үзенчә сайлый
Кунар өчен гөлләрне.
Әйтик, сиңа унсигез яшь,
Бер чибәргә күз төшә.
Сүз катасың, озатасың —
Гәп куера, сүз «пешә».
Иреннәр тия иренгә,
Сизмичә дә каласың.
Сайратасың күкрәгеңдә
Гүя былбыл баласын.
Их, яшьлекнең кабатланмас
Шул гүзәл мизгелләре!
Сөйгән ярларның балкыган
Кояштай йөзлеләре.
Мондый чакта танышыр өчен
Хәтта сүз артык була.
Бер караш белән күңелне
Күңелгә тартып була.
Әзмени безнең арада
Нәкъ шулай танышканнар:
Бер карап танышканнар һәм
Мәңгегә кавышканнар.
Хәер, минем әйтер сүзем
Алар турында түгел;
Яшьлек үзе кавыштырган
Парлар турында түгел.
Дөньяда бит әле, дуслар,
Аерылган парлар да бар.

Яңадан иш таба алмый
Интеккән җаннар да бар.
Бүген сезгә сөйләячәк
Сүзем дә шул турыда,
Ягъни үзенең парын җуйган
Ялгыз бер тол турында.
Анкетасын да тутырыйк:
Исемнәре — Искәндәр.
Аның хәлен аңлар микән
Парлы гомер кичкәннәр.
Героем әле карт түгел,
Кырык-кырык бишләрдә.
Тәҗрибәсе дә күп түгел
Гыйшык-мыйшык эшләрдә.
Кем әйтмешли, нибарысы
Бер өйләнеп караган.
Һәм үзен күпмедер вакыт
Бик бәхетле санаган.
Ләкин бәхет дигән нәрсә
Була шул кунак кына:
Чытлык кыздай күпләр белән
Ала ул уйнап кына.
Безнең героебыздан да
Бәхет шулайрак көлгән:
Качып киткән яшь кәләше
Бер фырт лейтенант белән.
Дөрес, лейтенант белән дә
Ул озак торалмаган:
Бик кәттә бер капитанны
Хатыныннан урлаган.
Бәлки әле, йөри торгач,
Генерал да табар ул.
Генералның улы булса,
Аның күңлен яулар ул.
Хәер, монсы башка сюжет,
Һич тә кагылмый безгә.
Сезне артык ялыктырмый
Күчик әле төп сүзгә.
Безнең сүз яшьли тол калган

Ир турында иде бит,
Ялгызлык диеп аталган
Чир турында иде бит.
Гәрчә җирдә хатын-кызлар
Күп булса да ир-аттан —
Сайлый башласаң, берсе дә
Булмый көткән, яраткан.
Кем акыллы, кем бик юләр,
Әйтер идем дөньясын!
Белмисең кай кочакта эреп,
Кай кочакта туңасын.
Аһ, тагын кереп киттем мин
Лирик чигенешләргә.
Ә һаман парын тапмаган
Герой белән нишләргә?
Әллә үзенә бер гүзәлне
Гашыйк иттерергәме,
Хикәямне түгәрәкләп
Шунда бетерергәме?
Юк, хәзер бит яучылыкны
Бик шәп үти игъланнар.
Бәхетен сынап карасын
Ялгыз зарыккан җаннар.
Аһ, менә кайда икән бит
Дөньяның алтыннары:
Чибәр, уңган, сабыр, эшчән,
Акыллы хатыннары.
Һәммәсе дә зифа буйлы,
Һәммәсе шәп холыклы.
Һәммәсе дә эшкә оста,
Һәммәсе дә булдыклы.
Безнең каһарманыбыз да
Нәкъ эзләгәнен тапты.
Бер асыл затның сүзләре
Җанына май булып ятты.
Үзем яшь, чибәр, дигән ул,
Эш белә, дигән, кулым.
Тик менә тормышта гына
Уңмады, дигән, юлым.

Торыр өчен үз йортым бар,
Шәһәр читендә генә.
Яшимен инде, кыскасы,
Муллык эчендә генә.
Йортыма да, үземә дә
Кирәк бер хуҗа, дигән.
Торыр идем шул вакытта
Күрми бер нужа, дигән.
Шартым да минем зур түгел:
Миңа яр булган кеше
Йорт эшләрен эшли белсен
Һәм булсын юмор хисе.
Булса әгәр бу дөньяда
Чын каһарман ир заты,
Көтәм шундый ирдән хәбәр
Яки бер сәлам хаты.
Шул көннән йөри башлады
Арада илче — хатлар.
Серләрне кәгазьгә түккәч
Якынайдылар ятлар.
Язылды иң кайнар сүзләр,
Кәгазь ничек түзгәндер?!
Эшләр кавышуга бара,
Укучым, шәт, сизгәндер.
Әйе, безнең каһарманның
Түзәр хәле калмады:
Китте тешләп карар өчен
Бәхет дигән алманы.
Эзләп тапты, барып керде,
Күрде бер гүзәл ханым —
Нәрсәдер бәйләп утыра,
Эшенә биреп җанын.
Алдында тегә башлаган
Бер күлмәге дә ята.
Кулында ул энәләрне
Ялт-йолт кына уйната.
Берсен тегә, берсен бәйли —
Күрсәң хәйран — тамаша.
Үзенең матурлыгыннан

Күзкәйләрең камаша.
Йөзе якты, айсыз төндә
Нур булып сибелерлек.
Билкәйләре шундый нәзек —
Өргәнгә бөгелерлек.
«Исәнмесез! Мин — Искәндәр.
Син Энҗеме, гүзәлкәй?» —
Сикереп торды хуҗабикә,
Аны яңа күргәндәй.
«Ә-ә, Искәндәр! Эшкә мавыгып
Күрми торам икән лә.
Менә син нинди баһадир!
Түргә уз, әйдә, әйдә.
Өс-башыңны чишенә тор,
Ә мин чәй куйыйм әле.
Күптән ир-ат сыйлаган юк,
Туйганчы сыйлыйм әле.
Аһ, хәерсез, чәй куярга
Юк икән өйдә суым.
Суга гына барып кайтчы —
Үземнең вакытым тыгын.
Күреп торасың, эшем күп —
Тегәм, чигәм, бәйлимен.
Бушка үткән минутларны
Чын күңелдән җәллимен».
Героебыз суга китте
Алып сыңар чиләген,
Кулы белән кысып тотып
Дөп-дөп иткән йөрәген.
Татлы уйларга чумды ул
Суга барган чагында:
«Кайнар коймак өелеп торыр
Кайтуыма табында.
Коймакны манып ашарга
Каймак булыр савытта,
Бәлки әле, кичке ашка
Суярбыз бер тавык та.
Үз йорты, үз хуҗалыгы,
Җитеш, әйбәт дөньясы.